ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 с.Старое Дрожжаное № 260

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен арттыру турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карары нигезендә һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәткә түләүне тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 мартындагы 151 номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына (24.01.2022 № 42, 30.01.2024 № 36 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1 пунктның дүртенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләме бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең вазыйфаи хезмәт хакы күләменә тапкырлап исәпләнә, ул 13 323 сум тәшкил итә.»;

**3 пунктның 3 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) вазыйфаи окладның 37 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;»;

**7 пунктның 4 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 37 проценты күләмендә;».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов